**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 26 октябрь | № 783

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем төзү турында» 2015 ел, 24 октябрь, 803 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем төзү турында» 2015 ел, 24 октябрь, 803 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 4 декабрь, 919 нчы, 2016 ел, 13 гыйнвар, 5 нче, 2016 ел, 18 февраль, 102 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын гамәлгә ашыру буенча эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын тормышка ашыру буенча эшче төркем турында нигезләмәдә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын тормышка ашыру буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) Татарстан Республикасы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендә яңа инвестицион проектларны тормышка ашыру өчен кирәкле инфраструктура объектларын төзү һәм (яки) төзекләндерү буенча чараларны тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы чыгымнарын финанслашу турында 2015 ел, 25 сентябрь, 06-22-05 нче һәм 2016 ел, 11 август, 06-22-13 нче килешүләр (алга таба – Килешү, Чаллы моношәһәре) нигезендә төзелде.»;

4.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Эшче төркем җитәкчедән, җитәкченең ике урынбасарыннан, эшче төркем секретары һәм әгъзаларыннан гыйбарәт.»;

әлеге карар белән расланган Чаллы моношәһәрен үстерү чараларын тормышка ашыру буенча эшче төркем составында:

эшче төркем составыннан М.А.Колесниковны чыгарырга;

эшче төркем составына кертергә:

| | |
|---|---|
| Нехаева Анастасия Александровнаны | «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциягә карамаган оешманың комплекслы проектларны тормышка ашыруны озата бару һәм мониторинглау идарәсе консультантын, эшче төркем җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков